**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 14 ноябре** **№5**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яңа Каенсар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставынының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Яңа Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Каенсар авылы, Гарарин урам, 34а адресы буенча урнашкан кибет янында үткәрергә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Яңа Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Яңа Каенсар авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Яңа Каенсар авылында суэтем башнясын һәм суүткәргечне карап тоту һәм ремонтлау проект-смета документлары;
- Яңа Каенсар авылы чишмәсен ремонтлау, проект-смета документлары;
- Яңа Каенсар авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Яңа Каенсар авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру: проект - смета документлары.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Важашур авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов